ISSN 0868-4545

2/91
Февраль

Салават күпере



Кыш бабай һәм Бөдрә-кәй МАҖАРАЛАРЫ

(Ахыры. Башы 1нче санда)































© «Салават күпере», 1991 ел.



















Тапкырга-табышмак


Киттем дип китә,
Кире килә.

(Итек).


Урманда бөккән,
Өйдә теккән.
Өр-яңа савыт —
Тишелеп беткән.

(Иләк).

Түгәрәк эчендәге хәрефләрне сүз килеп чыгарлык итеп тоташтырыгыз.



Түгәрәк эчендәге хәрефләрне тоташтыручы сызык буйлап барып, биредә нинди сүз язылганын белегез.



Айзирәк

(Шәехзадә Бабич шигыре)

Исемең синеке, ускәнем?

Айзирәк кыз, зирәк кыз, үткер теле,
Изгеләрдән изгерәктер, юктыр кере,
Күзләр — тылсым, сүзләр — әфсен, йөзе —
әфлисун,
Аның кебек оҗмахында юктыр хуры...

АЙЗИРӘК — татар-фарсы сүзе. Акыллы, бик зирәк дигән мәгънә белдерә. Борынгы йола буенча, кичен ай калыкканда яки ай тулысында туган балаларга АЙ сүзе кергән исем кушылган.



Гөлчирә

(Татар халык җырыннан)

Түр тәрәзә яннарында
Энҗе сайлый Гөлчирә.
Озын керфекләре аша
Күзләреннән нур сибә.

Ай-һай матур Гөлчирә,
Энҗе-мәрҗәннәрне тезеп,
Гөлчирә калфак чигә...

ГӨЛЧИРӘ (ГӨЛЧӘҺРӘ) — фарсы сүзе. Гөл йөзле, гөл чырайлы дигән мәгънә белдерә.

Кадерле балалар!
Сездән иң матур исемнәр турында шигырьләр, такмаклар көтәбез.

Рәссам Лилия ЗОЛОНДИНОВА



Наилә Яхүн
Өч туган

Биектә-биектә, ак болытларга уралган таулар арасында, өч туган яшәгән. Бу өч туганның өчесенең дә тылсымлы су сиптергече булган. Зәңгәр күзле Кече туган су сиптерергә бик тә яраткан. Ул су сиптергән чакта урамнардан шаулап гөрләвекләр аккан, агач ботакларында яшел яфраклар пәйда булган.



Аннары Уртанчы туган эшкә тотынган. Җирне ул туйганчы су белән коендырган — җылы бөркеп яткан күлдәвекләрдән, чыркылдый-чыркылдый, малайлар йөгерешкән.



Өлкән туган исә кайчан карама моңсу икән. Суны ул сиптергеченнән бик озаклап, акрын гына сиптергән. Агачлардан туңган-өшегән яфраклар коелган. Алар зур, салкын күлдәвекләрдә катып ятканнар. Тора-бара күлдәвекләр бозга әйләнгән...

Шулай бер көнне Кече туган иртән иртүк уянган. Менә ул бер авыр сиптергечне эләктереп алган да, мышкылдый-мышкылдый, ашыга-кабалана су сиптерә башлаган. Әмма ул куе томан эчендә сиптергечләрне бутаган булган шул. Ялгыш Өлкән туганныкын эләктергән. Зәп-зәңгәр күк йөзе төсен җуйган, әле агарган, әле соры төскә кергән. Яшел яфраклар, саргаеп, агачлардан коела башлаганнар, ә явыз җил аларны куалап йөрткән, урам ташларына сылаган... Кешеләр җылы киемнәр кигәннәр, кулчатырларын баш очына күтәргәннәр, күк йөзенә карана башлаганнар.

Бәхеткә каршы, шул чагында Уртанчы туган белән Өлкән туган Кече туганның кулыннан су сиптергечне тартып алган. Оятыннан Кече туган бик озак җылаган, аның күз яшьләре агач яфракларында, үләннәрдә, чәчәк таҗларында энҗе чыклар булып җемелдәгән...

Шаян малай тәртип бозуын әле дә дәвам иттерә булса кирәк, югыйсә ни өчен көтмәгәндә кышын яңгыр явып китә, ә җәйге челләдә кинәт боз ява башлый?

Рәссам Йосыф ВӘЛИӘХМӘТ



ХУШ КИЛӘСЕЗ! РӘХИМ ИТЕГЕЗ!



Әйдүк, әйдүк! Түрдән узыгыз!

Кунакны сезнең өйдә дә шулай дип каршылыйлардыр. Кыюсызланып, оялыбрак торучыны искәрсәләр, «Бер дә тартынмагыз, үз өегездә утыргандай иркенләп утырыгыз»,— дип әйтеп җибәрәләрдер. Табын янында кыстап-кыстап ашаталардыр. Французлар, әйдә, кыстамасын, аларда гадәт шундый. Ә без, татарлар, кыстый-кыстый сыйлыйбыз. «Чәкчәгеннән авыз итегез», «Кош телен кабып карагызчы»,— дибез. Кунакны: «Гаеп итеп китмәгез, берүк. Тагын килегез»,— дип озатабыз.

Моңа өстәп тагын шуны белегез: ТҮБӘНЧЕЛЕКЛЕ хуҗа булу — кунакның теләгән бик тиз аңлап алу, үтәргә тырышу дигән сүз; ЮМАРТ хуҗа булу — кунаклар өчен уенчыкларыңны, китапларыңны, маркаларыңны кызганмау дигән сүз; ЭЧКЕРСЕЗ хуҗа булу — кунактан рәхмәт таләп итмәү, бүләк көтмәү, мәшәкатьләрдән зарланмау дигән сүз; ӘДӘПЛЕ хуҗа булу — кунакның ялгыш кына җибәргән хаталарын искәрмәү, кунакны уңайсыз хәлгә куя торган «кызыклар» ясамау дигән сүз; ТӘРБИЯЛЕ хуҗа булу — югарыда әйтелгәннәрнең барысын да үтәү дигән сүз.





Ләбиб ЛЕРОН

КУЯННАР САНАМЫШЫ

Бер, ике, өч...
Куяннарда бөтен көч!
Дүрт, биш...
Безне җиңеп булмый һич!
Алты, җиде...
Куркаклар башын иде!
Сигез, тугыз, ун...
Алты бүре — алты тун!
Без тук бүген, бүре ач —
Әнә килә, тизрәк кач!

Хәкимҗан ХАЛИКЪ

ТӨЗӘЙТКЕЧ


«Тиз әйт! Тиз әйт!
Тизрәк! Тизрәк!
Тиз! Тиз! Тиз!» — ди
Тизәйткеч.
Тизәйткеч ул
Тиз әйттереп,
Телебезне
Төзәйткеч.

ӘЙБӘТ КАРШЫЛАГАН

МӘЗӘК

— Әни, без Сания апаларга телевизор карарга кердек.
— Йә, ничек каршылады соң?
— Бик әйбәт каршы алды. Ишектән керүгә: «Сез генә җитмидер идегез!»— диде.

Рәссам Светлана ИБРАҺИМОВА



Иман рисаләсе

УЗГАН САБАКНЫ КАБАТЛАУ

(1 нче сан, 1991 ел)

Сөаль:

— Кеше ни-нәрсә белергә тиеш?

Җавап:

Әүвәл Аллаһы тәгаләне белергә тиеш.

ИКЕНЧЕ САБАК



Сөаль:

— Аллаһы тәгаләгә нинди зат дип иман китерәсең?

Җавап:

— Аллаһы тәгалә — камил сыйфатлар белән сыйфатланган, затында тиңдәше һәм охшашы юк, барча нәрсәне юктан бар кылган, барча галәмне тәрбия кылучы.

Аллаһы тәгалә нәрсә теләсә, шул була һәм нәрсә теләмәсә, шул булмый.

Гыйбадәткә тиешле бары ул Алладыр, башка гыйбадәткә тиешле Алла юк дип иман китерәмен.

Сәхифәне Фәрит ЯХИН алып бара.

Рәссам Надир АЛЬМЕЕВ

Марат Закир

КЫШНЫҢ СОҢГЫ ТӨСЛӘРЕ



Зәңгәр чыршы, зәңгәр тынлык,
Зәңгәр кар, зәңгәр болытлар...
Калган төсләргә буярга
Рәссам-кыш, ахры, онытакан.

...Кинәт кар-тауның артыннан
Калкып-балкып чыкты кояш!—
Җиһан төсләр белән тулды,
Нурына аның коенгач.

Инде янә бер мизгел һәм...
Күзләр чагыла төсләрдән;
Алтын алма, кызыл алма —
Күр!— кызылтүшләр, песнәкләр!..

Касыйм Тәхау

Үсегез, җиләкләрем!



Сыгылмалы көянтәм,
Чәчәкле чиләкләрем.
Йөгерә-йөгерә су ташыйм:
«Үсегез, җиләкләрем!»

Алсу кояш нурында
Сез кызарып пешәрсез...
Әби белән икәү без
Җиләкләп чәй эчәрбез.

Рәссам Айдар ҮТӘГӘН





— Бүген тышта бик салкын. Туныңны ки, җылыда йөртер үзеңне,— диде әни иртән.

Мин пальто, куртка, плащлар эленеп торган кием элгече янына килдем. Тунымның эчен-тышын кулларым белән капшап чыктым, йонынннан сыйпадым. Бер җылысы да юк иде тунның. Ничек җылыта микән ул? Мич түгел бит инде, батарея да түгел.

Урамга чыккач та шушы сорау тынгы бирмәде. Җавабын үзем таба алмадым, узган-барганнан белешергә дә җай чыкмады. Барысы да салкыннан куырылганнар, артларыннан кемдер куган кебек йөгерешәләр.

Өйгә кергәч тунымны тотып карасам, җып-җылы! Менә сиңа мә! Әллә чынлап та җылыта торган хикмәте бармы?

— Тун үзе җылытмый, билгеле, җылы бирми ул,— диде әни чәй ясый-ясый.— Ә син туныңның нигә шулай калын итеп тегелгәнен беләсеңме? Мамык һәм йон арасында һава саклансын өчен шулай иткәннәр аны.


— Нигә кирәк соң ул һава?

— Һава безнең тәнебездән чыккан җылыны саклый, тәнгә туңарга ирек бирми. Һава бит җылыны да, салкынны да начар үткәрә. Пыяла су үткәрмәгән шикелле. Әнә бит, стаканнан чәй саркып чыкмый. Мамык белән йон арасындагы һава да тәнебезгә салкын кертми, тәннең җылысын читкә чыгармый. Тәрәзәләрне нигә ике катлы итәләр дип уйлыйсың?

— Ике тәрәзә арасында һава була. Ул тыштан суыкны кертми, өйдән җылыны чыгармый!— дидем мин аңлаганыма куанып.

Әни аркамнан сөеп мактап куйды.

Рәссам Заһир ХӘКИМ



Ага Базар



Шулай итеп, «Вакыт машинасы» Булат белән Сөмбелне мең дә бер йөз еллар элгәре заманнарга алып китте. Алар Бөек Болгар шәһәренең калын диварларына карап тордылар да кире елга ярына борылдылар. Анда бик күп кеше җыелган иде. Якынрак килгәч, аның зур базар икәнен белделәр. Ул Ага Базар дип атала икән. Халык бөтен болынны биләп алган. Тавыш, ыгы-зыгы. Берәүләр сата, берәүләр ала. Күптән түгел генә Булат әтисенә ияреп Казан базарына барган иде. «Мең ел үтсә дә, дөнья үзгәрми икән»,— дип уйлады ул.

Булат бер мизгелгә күзләрен учы белән каплады. Алтын кылычларның кояшта җемелдәве күзен камаштырган иде. Кара мыеклы сатучы абый елмаеп Булатны якын килергә чакыра. Янәшәсенә сызгырып оча торган уклар өелгән, озын сөңгеләр сөяп куелган, бизәкләп эшләнгән калканнар тезелгән.

Ә Сөмбел Булатның җиңеннән тотып читкә тарта. Анда елкылдап торган болгар күненнән тегелгән читекләр саталар. Янәшәдә үк сусар, кеш тиреләре җемелди, йорт биеклеге итеп паласлар өелгән.

Кинәт халык арасында ыгы-зыгы купты. Ярга җилкәннәрен киергән зур көймә килеп туктады. «Багдадтан килгәннәр!»— дигән тавышлар ишетелде. Көймәгә басма сузылды. Чалмалы гарәпләр ярга чыга башлады. Кайсыдыр мәчеттән: «Аллаһы әкбәр!»— дигән азан тавышы яңгырады.

Болгар-Биләр диясез,
Болгарданмы киләсез?
Болгар елкыларын һәйдәп,
Һинд илләрен гизәсез.

Җүкә ләнгәс — кәрәз балга,
Җам-аяклар — ачы балга,
Энҗе-мәрҗән, гәүһәр-якут
Агыла шәһри Болгарга.

Ләнгәс — *бал тәпәне.*
Җам-аяк — *малның бәкәл тиресеннән ясалган касә.*

Сәхифә Р. ЗӘЙДУЛЛА
хикәяләвендә бирелә.

Рәссам Рушан ШӘМСЕТДИН



Нинди генә уенчыкларым юк минем! Әле әти сатып ала, әле ерак әби белән бабай китереп китә, башка туганнар да бүләк итеп кенә торалар. Бер танк бигрәк тә шаккатмалы: төймәсенә бассаң, ыжылдап әйләнә башлый, көпшәсеннән утлар күренә. Ул танкны әти әллә кайсы бер шәһәрдән алып кайтты. Чынлап. Хәрби самолетларым да бар. Икәү! Корабль, туп, ракеталар... Хәтта автомат та!

Мин бу уенчыкларны зал уртасына таратып уйнарга тотынсам, әби колакларын томалап аш бүлмәсенә йөгереп чыгып китә. Чыдый алмый. Автомат берьюлы мең тегү машинасыннан чыккан тавыш белән сиптерә, самолетлар улый, туплар гөрселди... «Куркам мин»,— ди әби һәм аш бүлмәсенә чыгып китә. Чынлап.

Шулай да пистолетым юк иде әле минем. Бакчадагы бөтен малайда диярлек бар, ә миндә юк иде.

Күрсәләр икән алар мине бүген: абый миңа да пистолет бүләк итте. Пис-то-л-л-лет! Яңа уенчыгымны күкрәгемә кысып яраттым, яңакларыма тидереп иркәләдем...

Кич белән безгә Фәрит керде. Күрше малае ул, иң якын дустым.

— Менә минем нәрсәм бар!— дип мактана-мактана атып та җибәрдем. Пистолетымның тавышы шәпме, янәсе.

Кинәт Фәрит идәнгә авып төште.


Мин елый-елый дустымны селкетә башладым, торгызмакчы булдым. Ул арада әни белән әби, абый йөгерешеп килеп җиттеләр.

— Юри генә, уйнап кына атканыем,— дип акландым мин яшь аралаш.— Кинода күргәнчә итеп атып караганыем...

— Мин дә чынлап үлмәдем!— дип сикереп торды Фәрит.— Ата башласалар, кемдер егыла бит. Кинода гел шулай.

Башкалар эндәшмәде. Мин пистолетны идәннән алып абыйга суздым. Сүзсез генә алды. Аңлады.

Аннары әнидән кәгазь тартма сорап, бөтен «хәрби техника»ны шуңа тутырдым. Абый тартманы караңгы шкафка тыгып куйды. Юк, үлмәсен Фәрит. Юри генә дә үлмәсен. Чынлап.



Рәссам Илдар ӘХМӘДИ



Бу рәсемдәге әйберләрне исемләп атап чык.




Рәсемне үзең буяп бетер.






Әлеге ике рәсем беренче карашка нәкъ бер төсле. Игътибар беләнрәк карасаң, җиде аерма табарсың. Таптыңмы!



Ә хәрефеннән Т хәрефенә кадәр барып кара әле. Кызыклы бер сүзгә юлыгырсың. Нинди сүз ул!



Үзе мич башында, үзе тун ябынып йоклый.

Менә сиңа табышмак. Җавабы болай... Юк, әйтмибез, үзең тап. Нокталарны карандаш белән тоташтырсаң, җавап-рәсем ясалыр.

Рәссам Зөфәр ХӘКИМ

КИРЛЕМӘН КИҢӘШЛӘРЕ

Әгәр әниең: «Эшкә соңга калам инде!» — дия-дия, ашыга-ашыга сине киендерергә азаплана икән, киенмәскә тырыш. «Бу оекбашны кимим! Күлмәкнең бусы ошамый!» — диген. Тыпырчына-тыпырчына җыларга тырыш. Берәр җиреңә «чәп» иттереп тә алсалар, отыры кычкырыбрак җыласаң да ярый. Шәрран ярып акырганыңны ишеткән күрше-күләннәр сиңа бик сокланырлар: «Карале, безнең күршедә генә нинди җылак бала үсә икән! Бигрәк матур итеп җылый инде!»— диярләр.

Җылыйсың килми башласа, көчәнмә. Көчеңне сакла. Әле синең киреләнә-киреләнә җылыйсыларың көне буена шактый булачак.



Рәссам Елена ХИТРОВА

Салават күпере

2 (12) — 1991

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ СОВЕТ-ФИН УРТАК ПРЕДПРИЯТИЕСЕ «ПОИНТ» ЖУРНАЛЫ

1990 ЕЛНЫҢ МАРТ АЕННАН БИРЛЕ ЧЫГА

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Җаваплы сәркатип
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Айдар ҮТӘГӘН

Исәп-хисап бүлеге
Розалия ЗАРУБИНА

Тышлыкта Рушан ШӘМСЕТДИН рәсеме

КПССның Татарстан Республика комитеты нәшрияты
Казан, Декабристлар, урамы, 2.

«Салават күпере» ежемесячный журнал Правления Союза писателей ТССР и Советско-Финского совместного предприятия «ПОИНТ» (на татарском языке). Основан в 1990 году.

Адрес редакции: 420012, Казань, ул. Комлева, 14. Редакция журнала «Салават күпере».

Производствога бирелде 22.01.91 ел. Басарга кул куелды 05.03.91 ел. Кәгазь форматы 84×108 $^{1}/_{16}$. Басма табак 1,0(2,1). Нәшер-хисап табагы 3,09. Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 25 мең данә. Заказ И-37. Бәясе 1 сум.




Бәясе 1 сум